# Сәламәтлек аланы.

Катнашалар:
Шүрәле
Төлке
Куян кызлары
Тиен кызы
Бүре малайлары
Аю малайлары
( Ике куян сикереп, йөгерешеп чыга. )

***1 нче куян.***

Борын- борын заманда
Кәҗә команда,
Саескан сотник,
Үрдәк урядник
Булган урманда.

***2нче куян.***

Бик елак та булмаган,
Бик тәртип тә бозмаган,
Бик ялкау да булмаган
Бер Шүрәле яшәгән.

***1 нче куян.***

Яшәгән, ди бу Шүрәле,
Бик зур газап кичереп,
Бөтен тәне сызлавыннан
Яшәгән, ди ул, интегеп.

***2 нче куян.***

Китапларны ятып укып
Күзләре кысылып беткән.
Бармаклары кәкре- бөкре,
Тешләре череп беткән.

***Барысы бергә.***

Хәле начар булганлыктан,
Бөтен күңеле тулган, ди.
Чөнки бу Шүрәле белән
Менә нәрсә булган, ди.

**Беренче күренеш**

*Урман. Агачлар рәте. Шомлы музыка яңгырый. Хәлсез, күзлек кигән Шүрәле керә. Ул бармакларының, тәннәренең сызлавыннан түзә алмыйча үкереп, кычкырып керә.*

***Шүрәле.***

Зур газап эчендә бүген кызарып туды таңым,
Сызлыйдыр бармак тәннәрем.
Кем соң дәвалар мине?
Аһ, үләм. Харап булдым ич,
Коткарыгыз сез мине.
У-у-у. Үләм.

*(Шулвакыт агачлар артыннан спорт киемнәре кигән Төлке күренә. Шүрәле аны качып-посып күзәтеп тора. Төлке җырлый-җырлый керә. Җырлап бетергәндә генә Шүрәлене күрә һәм куркып китә.)*

***Төлке***. Син кем?

***Шүрәле.***

Курыкма син, өрекмә син,
Мин шыксыз Шүрәле түгел.
Өстерәлеп кенә йөрим,
Сәламәтлегем нык түгел.
***Төлке (***көлеп)

Шүрәле, нинди Шүрәле?
Мондый Шүрәле була димени?
Бармакларың кәкрк-бөкре
Күзләрең кысылып беткән,
Тешләрең дә исән түгел,
Барысы да череп беткән.
Әллә инде бөкрең дә бар?
Кит инде, шул яшеңнән!
Дәваланырга кирәк сиңа
Кичекмәстән, күптәнән.

***Шүрәле.***

У-у-у. Әйтәм ич, мине берсе дә танымый. Нишлим соң, Төлке дус. Киңәш бир.

***Төлке.***

Менә миңа син кара,
Бармакларга, колакка.
Күзлегем дә юк бит минем,
Буй-сыным да бик зифа.
Шүрәле.
Хәлләр начар, Төлкекәй,
Берәр серен әйтчекәй.
(аягына барып егыла, тезләнә.)

***Төлке.*** Я, я, ярый инде, ачам, ачам серемне. Мин былтыр бик матур аланга килеп чыккан идем.
***Шүрәле*** (бүлдереп). Ә-ә-ә (куркып). Былтыр, былтыр дисеңме? Мин куркам аңардан. (Кача башлый.)
***Төлке.*** Юк ла инде. Синең нинди былтырың булсын. Теге елны дип әйтүем. Сиңа дәваланырга кирәк. Кичектермәскә.
Серле алан мәктәбендә
Бик күңелле, ди анда.
Һичкемнең һәм һичкайчан
Кайтасы килми аннан.
Анда иң кирәклесе-
Исәнлек икән,
Сәламәтлек ачкычы
Шушында икән.
Шүрәле.
Белсзң иде, белсәң иде
Минем сызланганымны.
Әйдә ашыгыйк, көтеп тормыйк
Тагы кемдер чыкканны.

***Төлке.***
Ярый, әйдә киттек,
Тик минем бер шартым бар:
Уйнамасаң гына кети.
Чыгардым шундый карар.
***Шүрәле.*** Юк, юк, кытыкламыйм.(Китәргә җыеналар. Тик Шүрәле кузгалмый. Төлке артына борылса, Шүрәле утырып тора.)

***Төлке.***
Тор, әйдә нәрсә утырасың?
Нәрсә көтеп торасың?
Шүрәле.
Автобус.
***Төлке.***
Хәрәкәттә - бәрәкәт, дип
Әйткән бит синең бабаң.
Саф һаваны сулый – сулый
Барабыз әле, туган.
Раз, два, раз, два,
Һаваны иркен сула.

*(Музыка яңгырый, бергәләп китәләр, Төлке артыннан Шүрәле өстерәлеп кенә бара. Агачларны бер тапкыр әйләнәләр. Шулвакыт тукткп калалар. Икенче яктан агачлар артыннан ике Куян уйнаклап килеп чыга.)*

***Төлке***.
Чү, тукта. Карыйк әле,
Болар кая баралар?
***(Музыка уйный. Куяннар сикерешеп керәләр.)***

***1нче куян.***

Иртә белән торабыз,
Битебезне юабыз,
Сабын белән юынгачтын
Бигрәк матур булабыз.
***2нче куян.***
Аш алдыннан һәрвакыт
Кулыбызны юабыз.
Чиста итеп, пөхтә булып,
Ашарга утырабыз.
***1нче куян.***
Кичен аякларыбызны
Сабын белән юабыз.
Юынырга яратабыз,
Без бик чиста торабыз.
***2нче куян.***
Иртәсен дә һәм кичен дә
Тешләрне чистартабыз.
Җемелдәп ялтырап тора
Таза нык тешләребез.
*(Сумкаларын куеп, юыну хәрәкәтләре ясап бииләр. Аннары йөгерешеп чыгып китәләр.)*
***Төлке.***
Менә күрдеңме, Шүрәле,
Алар кая талпына?
Әйдә, без дә соңга калмыйк,
Барыйк алар янына.
*(Чыгып китәләр.)*
Икенче күренеш.

*Урман аланлыгы. “Сәламәтлек мәктәбе” дигән плакат эленгән. Утлар җем – җем итә. Җәнлекләр йөгерешеп йөри. Музыка уйный, җәнлекләр күнегүләр ясый. Шуннан соң Төлке Шүрәлене алып керә. Музыка туктый, ңәнлекләр аларны чолгап ала.*

***Төлке.***
Дусларым, исәнмесез,
Хәерле көннәр сезгә!
Менә күрегез дустымны,
Дәвалау кирәк безгә.
Бармаклары кәкркүе – бөкре,
Күзләре кысылып беткән,
Тешләре дә исән түгел,
Барысы да череп беткән.

***Җәнлекләр.(***барысы бергә)

Булышабыз, булышабыз,
Бик теләп булышабыз.

***1 нче җәнлек***. Тик безнең табышмакларның җавапларын тапса гына. *(Һәрберсе берәр табышмак әйтә.)*
Кечкенә генә кунача.

1. Утыз ике кодача
Утыралар кунакта.
2.Абыйсы белән сеңлесе күпер аркылы яшиләр,
Бер-берсен күрмиләр.
3. Икәү карап тора,
Икәү тыңлап тора,
Берәү сайрап тора.
4. “Ти”,-дисәң, тими,
“Тимә”,- дисәң, тия.
5. Сөяге юк, теше юк,
Сөйләмәгән сүзе юк.
6. Таралгач – биш,
Җыелгач – бер.
7.Җәен урманга патша,
Кышын кардан да аста.

***Куян кызы.***
Күрегез куян кызын,
Ничек итеп тырыша.
Шундый күнегүләр ясап
Исәнлеген ныгыта.
*(Куян кызы акробатик күнегүләр ясый.)*
***Аю баласы.***
Бигрәк төз, матур итеп
Күнегүләр ясыйлар.
Алар шулай тырышалар
Гәүдә тырышын саклыйлар.
*(Бүре малайлары бергәләп бииләр.)*
***Шүрәле.***
Коткаручыларны күзли – күзли
Талып бетте күзләрем.
Менә кемнәр кирәк миңа,
Менә бит газизләрем.
***Төлке.***
Шундый зур юллар узсак та,
Без сер бирмәбез бер дә.
Күбрәк хәрәкәтләнеп,
Сәламәт яшик бергә.
*(Барысы да җыелып басалар.)*
***Барысы бергә.***
Күрдегезме, бу тамаша
Гыйбрәтле һәм хикмәтле.
Саклагыз сез, кадерләгез
Изге сәламәтлекне.
*(Барысы бергә “Физзарядка” җырын башкаралар.)*